**Татарстан Республикасы**
**Зәй муниципаль районы Поручик авыл җирлеге Советы**

# КАРАРЫ

**№ 150** **22.04.2019 ел.**

**"2018 елда Зәй муниципаль районы**
**Поручик авыл җирлеге бюджеты**
**үтәлеше турында"**

Россия Федерациясе Бюджет кодексы, Татарстан Республикасы Бюджет кодексы, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Поручик авыл җирлеге Уставы нигезендә, Зәй муниципаль районы Поручик авыл җирлеге Советы

**карар бирә:**

1. 2018 ел өчен Зәй муниципаль районы Поручик авыл җирлеге бюджеты үтәлеше турында хисапны керемнәр буенча 5777,6 мең сум, чыгымнар буенча 6088,6 мең сум, керемнәрне чыгымнардан 311,0 мең сумга арттырып, һәм түбәндәге күрсәткечләр белән расларга:

1.1. 2018 ел өчен бюджет кытлыгын финанслау чыганаклары буенча әлеге карарга 1нче кушымта нигезендә;

1.2. 2018 ел өчен бюджет керемнәре буенча әлеге карарга 2нче кушымта нигезендә;

1.3. ведомство структурасы буенча бюджет чыгымнарын 4нче кушымта нигезендә һәм чыгымнарның функциональ структурасы бүлекләре, бүлекчәләре, максатчан статьялары, чыгымнар төрләре буенча 2018 ел өчен бюджет чыгымнарын бүлүне әлеге карарга 3нче кушымта нигезендә.

2. Поручик авыл җирлеге башкарма комитетының Резерв фонды исәбенә Поручик авыл җирлеге бюджеты ассигнованиеләрен файдалану турындагы хисапны әлеге карарның 5 нче кушымтасы нигезендә игътибарга алырга.

3. Карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында" (PRAVO.TATARSTAN.RU), Зәй муниципаль районы Поручик авыл җирлеге сайтында (http://zainsk.tatarstan.ru/poruchikovskoe.htm) урнаштырырга.

4. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көннән үз көченә керә.

5. Карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

**Поручик авыл җирлеге башлыгы** **П.С. Уразайкин**